Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 15 нче “Алсу” балалар бакчасы
мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем учреждениясе

# Уртанчылар төркемендә
# танып белү юнәлеше буенча белем бирү эшчәнлеге
# Тема: “Тылсымлы шар”

Өлкән тәрбияче Рәхимова Н.Р.
Тәрбияче Мөбарәкшина Л. М.

2016-2017уку елы

**Максат:**

Балаларда әйләнә- тирәне кабул итүне камилләштерү, тәҗрибә һәм танып белү эшчәнлегенә карата кызыксыну үстерү.

**Бурычлар:**

1. Балаларның һава турында белемнәрен баету һәм ныгыту; кеше, хайваннар һәм үсемлекләр тормышында һаваның әһәмияте турында күзаллауларын киңәйтү.
2. Гади тәҗрибәләр аша балаларда тикшерү һәм нәтиҗә ясый белү сәләтен үстерү; тикшерү эшчәнлегенә кызыксыну тәрбияләү.
3. Балаларны твстинг техникасы белән таныштыру, модельле фикер йөртү һәм үрнәк буенча ясау сәләтен, хәрәкәт координациясен һәм моторикасын үстерү.
4. Балаларда күзәтүчәнлек, фикерләү сәләтен һәм сөйләм телен үстерүне дәвам итү. Тирә-юньдә күргәннәрдән чыгып нәтиҗә ясый белү күнекмәләре тәрбияләү.

Әзерлек эше: һава температурасын күзәтү, һава темасына уеннар өештыру; һаваның кеше тормышында, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясындагы роле темаларына әңгәмәләр үткәрү. Шардан ясалган төрле фигураларның рәсемнәрен карау.

Җиһазлау: шарлар, сабын куыклары, проектор, экран, полиэтилен пакетлар, сыбызгылар, фонограмма, магнитафон, видеролик, үлчәү, алъяпкычлар һәм баш киемнәре.

**Эшчәнлек барышы:**

Балалар. Балалар, бүген мин сезнең белән кызыклы чара үткәрергә булдым. Әйдәгез әле бер- беребезгә карап елмаейк һәм хәерле иртә диик. Мин сезгә яхшы кәеф һәм бер- берегезгә карата игътибарлы булуыгызны телим.

Карагыз әле, безнең балалар бакчасы почтасына видео хат килде. Бу хатны безгә Винни Пух җибәргән. Әйдәгез бергәләп бу видионы карап китик. (*видиоролик тыңлана*)

"Исәнмесез балалар. Күптән түгел мин Пятачокта кунакта булдым. Ул миңа һава шары бирде һәм нигәдер әйтте, бу шар гади түгел, ә тылсымлы. Бер нәрсәдә аңлыйм, тылсымы нәрсәдә икән? Балалар, бәлки сез миңа аңлатырсыз? Сезнең җавапларыгызны бик тә көтеп калам".

Тәрбияче. Балалар, Винни Пухка ярдәм итәбезме? (*Әйе*)Минем уйлавымча бу дөрестән дә тылсымлы шар.
Уйлап карыйк әле, ни өчен ул һава шары диеп атала соң?

Балалар. *чөнки шар өчендә һава бар*

Тәрбияче. Ә хәзер мин сезгә табышмак әйтәм, игътибар белән тыңлагыз:

Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мөмкин түгел. Бу нәрсә?

Балалар. Һава.

Тәрбияче. Бүгенге чарада без сезнең белән үзебезне кызыксындырган сорауларга җавап биреп карарбыз: нәрсә ул һава, нәрсәдән тора, ни өчен кирәк булуын ачыкларбыз.

Балалар! Ни өчен без һаваны күрмибез, ишетмибез һәм тоймыйбыз.
Балалар. Чөнки күзгә күренми.

Тәрбияче. Әйдәгез кечкенә тикшерүчеләргә әйләнеп, берничә тәҗрибә үткәреп карыйк әле. Моның өчен безгә лаборатория һәм тикшерүләр үткәрү өчен киемнәр кирәк. Ягез әле киенеп эшкә керешик.

**1 нче тәҗрибә.**

Тәрбияче. Иң беренче тәҗрибәбез: һаваны күреп буламы? Моның өчен безгә полиэтилин пакетлар кирәк булачак, алар сезнең каршыгызда. (*балалар пакетларны ала*)

Тәрбияче. Алсу кара әле, пакетның эчендә нәрсә бар?

Алсу. Пакет буш.

Тәрбияче. Әйе, ул буш, аны берничә тапкыр бөкләргә мөмкин .

Тәрбияче. Ягез әле,балалар, тирә ягыгыздагы һаваны пакетка җыеп, борып куейк. Рифат, нәрсә булды пакетларга?

Рифат. Формасын үзгәртте, ул һава белән тулды.

Тәрбияче. Дөрестәндә пакет һава белән тулды.

Тәрбияче. Ләйлә, синең пакетың нәрсәгә охшаган?

Ләйлә. Минем пакетым мендәргә охшаган

Тәрбияче. Искәндәр, ә синеке нәрсәгә охшаган?

Искәндәр. Минем пакетым песигә охшаган.

Тәрбияче. Рөстәм, Һаваны без күрәбезме, аның төсе бармы?

Рөстәм. һаваның төсе юк.
Тәрбияче. Әйдәгез пакетны ачып, һаваның исен иснәп карыйк эле. Исе бармы? Зөлфия, син ничек уйлыйсың?
Зөлфия: һаваның исе юк.
Тәрбияче: Камил, нәрсә үзгәрде?
Камил. Пакет кабат буш калды, чөнки аның эчендәге һава бушады.
**Нәтиҗә ясыйк:** һава үтә күренмәле, төссез, иссез булуын без сезнең белән ачыкладык. Димәк, һава безнең тирә ягыбызда бар ул.

**2 нче тәҗрибә.**

Тәрбияче. Нәни тикшерүчеләрем, әйдәгез алдагы тәҗрибәгә күчик. Ә менә минем беләсем килә, безнең өчебездә һава бармикән? Илсаф, син ничек уйлыйсың?
Илсаф. Әйе, безнең эчебездә һава бар.
Тәрбияче. Ә аны ничек тикшереп була соң?
Балалар. Шарны тутырып карап була.
Тәрбияче. Әйдәгез әле барыбыз да шарларны алып, аны эреп тутырып карыйк. (*шарларны тутыралар һәм бәйләп куялар*)
Тәрбияче. Камил, нәрсә белән тулды шар?
Камил. Шар һава белән тулды.
**Нәтиҗә ясыйк:** Димәк безнең өчебездә һава бар. Без шул һава белән шарларны тутырдык.

**Физминутка.**

Тәрбияче. Нәни тикшерүчеләрем, сез арыгансыздыр, бераз ял итеп, уйнап алыйк. Мин "Сабын куыклары" алып килдем, шуларга эреп куыклар тутырырмын, ә сез шул куыкларны кулыгыз белән шартлатырсыз. Әйдәгез әле кем күбрәк сабын куыкларын шартлатыр икән?! (*уен уйнала*)
Тәрбияче. Алсу, син ничек уйлыйсың менә шул куыклар өчендә һава бармы?
Балалар. Әйе, куыклар эчендә һава бар.
Тәрбияче. Зөлфия, ул нинди авырлыкта?
Балалар. Һава җиңел.
Нинди **нәтиҗә** ясап була**:** һава җиңел булганга сабын куыклары очалар.

**3 нче тәҗрибә.**

Тәрбияче. Күңелле ялдан соң эшебезне дәвам итик. Алдагы тәҗрибәгә күчик. Ничек уйлыйсыз һаваның авырлыгы бармы икән ул, моны тикшкреп карыйк әле. Сезнең алдыгызда үлчәүләр, шул үлчәүләргә шарлар эленгән. Игътибар белән карагыз әле: шарлар барсыда бер тигезлектә, бер авырлыкта. Әгәр без бер шарны шартлатып карасак нәрсә булыр икән? (*шарны инә белән шартлаталар*)
Тәрбияче. Искәндәр, нәрсә үзгәрде?
Искәндәр. Шар шартлагач, бушады һәм җиңеләйде.
Тәрбияче. Рөстәм, ә син ничек уйлыйсың?
Бала. Һавалы шар аска төште, чөнки ул авырырак.
**Нәтиҗә ясыйк:** Димәк һаваның авырлыгы бар икән.

**4 нче тәҗрибә.**

Тәрбияче. Балалар, алдагы тәҗрибәбез: һаваны ишетергә мөмкинме икән ул? Ягез тикшереп карый әле. Моның өчен безгә гади сыбызгылар кирәк булачак, алар сезнең өстәлләрегездә. Әйдәгез бергәләп сызгырып карыйк әле. (*сызгыралар*)

Тәрбияче. Ләйлә, син ничек уйлыйсың һаваны ишетеп буламы?

Ләйлә.Әйе ишетеп була.

Тәрбияче. Ничек белдең?

Ләйлә. Сыбызгыдан сызгырып карадым

Тәрбияче. Камил, ә кайдан тавыш чыкты?

Камил. Сыбызгыга эргәч тавыш чыкты.

**Нәтиҗә ясыйк**: дөрестән дә, сыбызгыга каты итеп өргәндә, һава бик тиз сыбызгы аша үтә, шуннан тавыш барлыкка килә. Димәк, һаваны ишетергә була икән.

Тәрбияче. Нәни тикшерүчеләрем! Без бүген сезнең белән бик күп ачышлар ясадык. Тикшерүләр ярдәмендә һаваны күреп булуны, эчебездә һава булуны, һаваның тавышы барлыкны дәлилләдек. Ләкин мин сезне буш кул белән җибәрәсем килми. Сезгә кызыклы масстер класс тәгъдим итәм. Моның өчен безгә модельләр ясау өчен шарлар кирәк булачак. Алар сезнең алдыгызда. Шардан төрле уенчыклар ясау - ул твистинг дип атала. Мин махсус насос ярдәмендә шарларны тутырып, әзерләп куйдым. Без бергәләп йорт хайваны - этне ясаячакбыз.Игтибарлы булыгыз! Бергәләп эшкә керешик. Этне ясарга тотонабыз. Эшебезне этнең башыннан башлыйбыз, шарны әйләндерәбез. Ә колакларын ике өлештән ясыйбыз. Муенын, алгы аякларын ясаганда шарны борабыз. Ә менә бусы этнең гәүдәсе була. Ә хәзер арткы аякларын ясау өчен шарны әйләндерәбез. Ә калган өлеше коерыгы була. Менә безнең этебез әзер. Килеп чыктымы? Бу уенчык миннән сезгә бүләк булыр. Ә үземнең этемне мин Винни Пухка җибәрәм. ул моңа бик шатланыр.

**Нәтиҗә:** уенчык өчендә һава бар, без аны күрә, ишетә һәм тоя алабыз. Һава һәрбер җирдә безнең белән. Менә хәзер сез беләсез инде, ни өчен Винни Пухның шары тылсымлы булганлыгын.

Тәрбияче. Балалар, бүгенге чара сезгә ошадымы? Ә нәрсә истә калды?

Балалар. – Тәҗрибәләр ясау.

- Ә миңа сабын куыклары белән уен.
- Шардан эт ясау ошады.

Тәрбияче. Балалар, сез бүген белем бирү эшчәнлегендә бик теләп катнаштыгыз, күп белергә тырыштыгыз, тәҗрибәләр ясадыгыз һәм сорауларга дөрес җаваплар бирдегез. Өйгә кайткач эти-әниләрегезне дә шардан төрле фигуралар ясарга өйрәтергә онытмагыз.